УДК 811.512.145

***Н.М. Мифтахетдинова***

# Г. ШӘРӘФНЕҢ ГАРӘП ГРАФИКАСЫ НИГЕЗЕНДӘГЕ ТАТАР ЯЗУЫН РЕФОРМАЛАУ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

В статье рассматривается деятельность известного языковеда, тюрколога, историка Г. Шарафа в области реформирования старотатарской письменности в начале XX в. В своих выступлениях, научных трудах ученый приводит неоспоримые доводы в пользу сохранения для всех тюркских народов системы письма на основе арабской графики.

**Ключевые слова:** татарская письменность на основе арабской графики, кегель, латиница, реформа печатной арабской графики.

The article examines the activities of the famous linguist, Turkologist, historian G. Sharaf in the field of reforming the Old Tatar writing at the beginning of the twentieth century. In his speeches and scientific works, the scientist gives undeniable arguments in favor of preserving the writing system based on the Arabic script for all Turkic people.

**Keywords:** Tatar writing based on Arabic graphics, kegel, Latin, reform of printed Arabic graphics.

Узган гасырның егерменче елларында татарлар һәм гомумән төрки халыклар арасында гарәп графикасын латинга алыштыру мәсьәләсе көн үзәгенә куела. Матбугатта галимнәр, язучылар, мөгаллимнәр, җәмәгать эшлеклеләренең фикерләре басыла, киң җәмәгатьчелеккә аңлату эшләре алып барыла. Кулланылышта булган гарәп графикасындагы татар язуын заман таләпләренә туры китереп реформалау барышында камилләштерүне күздә тотучыларның берсе – тел галиме, язучы, җәмәгать эшлеклесе, тарихчы Галимҗан Шәрәф.

Галимҗан Шәрәф татар милләте тәрәккыятенә зур өлеш керткән атаклы бертуган Шәрәфләр нәселеннән. Шәрәфетдин һәм Гайнелнәвал ун бала тәрбияләп үстерәләр: Зифа, Сара, Һаҗәр, Халисә, Фатыйма, Шиһаб, Шәһер, Борһан, Гыйльми, Галимҗан. Аларның һәм дәвамчыларының эшчәнлекләре ислам дине, мөгаллимлек, язучылык, наширлек, фән белән бәйле. Аларның һәрберсе игътибарга лаек: гарәп мәдәнияте тарихы белгече, Г. Тукайның остазы Шәһер Шәрәф, күренекле педагог, журналист, дипломат Борһан Шәрәф, дөньякүләм атаклы беренче хатын-кыз астроном, физика-математика фәннәре докторы Шәфика Шәрәф һәм башкалар.

Бертуган Шиһаб, Шәһер, Борһан һәм Гыйльми Шәрәфетдиновлар 1906 елда «Матбагаи Шәрәф» исемле типография ачалар. Г. Тукайның үзе исән чагында басылган китаплары нәкъ менә шул нәшриятта дөнья күрә [Тәрҗеманов, 1989].

Казан лингвистика мәктәбенең күренекле вәкиле, татар-төрек теле фонетикасын тирәнтен өйрәнгән тел галиме Галимҗан Шәрәф 1896 елның 29 декабрендә хәзерге Буа районы Аксу авылында туа. Казанда танылган Мөхәммәдия мәдрәсәсендә белем ала һәм, үзлегеннән әзерләнеп, Казанның 2 нче реаль училищесына укырга керә. 1915 елда миллионер Хөсәенов акчасына оешкан Стипендия комитеты ярдәме белән Петроград тимер юл инженерлары институты студенты була. Шул ук елларда Петроград университетының тарих-филология факультетында ирекле тыңлаучы да. Танылган галимнәр В. Бартольд, В. Смирнов, А. Самойлович һәм башка профессорларның семинарларында катнаша, борынгы төрки телдә язылган Орхон-Енисей язмаларын өйрәнә [Әлтәф, 1990].

1917 елдан Казан университетында эшли, фәнни эшчәнлеген күренекле тюркологлар, тел галимнәре белән берлектә алып бара. 1919 – 1920 елларда Казан университетында Н.Ф. Катанов җитәкчелегендә – төрки телләр, Н.И. Ашмарин белән берлектә – чуваш теле, В.А. Богородицкий остазлыгында татар теле һәм гомуми тел белеме буенча эшли. Аның «Татар теле авазларының палятограммалары» исемле хезмәте дөньякүләм танылу ала [Шараф, 1927].

1921 – 1922 елларда ТАССРның Халык Мәгарифе Халык Комиссариаты Академүзәгенең Шәрык бүлеге мөдире вазифасын башкара. 1922 – 1937 елларда Шәрык (1931 елдан – Татар, 1934 елдан – Казан) педагогика институтында укыта, фәнни эзләнүләрен дәвам итә.

Кызганычка каршы Г. Шәрәф сәяси эзәрлекләүләргә дучар була, шул сәбәпле галимнең фәнни эшчәнлеген дәвам итү мөмкинлеге юкка чыгарыла. 1937 елның 20 февраленнән, «педагогия институтында оялаган халык дошманнарын фаш итү кампаниясе» кысаларында, институт җитәкчелеге аңа лекцияләр укуны тыя. Шул ук елның 23 мартында Г. Шәрәф кулга алына һәм, 1940 елның 27 февралендә «Советка каршы милләтче оешма эшендә катнашкан өчен», 8 елга ирегеннән мәхрүм ителә. Казанга 1945 елда кайта, әмма эшкә урнашу, Казанда яшәү хокукыннан мәхрүм була. Ул абыйсы Шиһабетдин Шәрәфнең кызы Бибинур янына Апаска китә һәм анда мәктәптә рус теле укытучысы булып эшли [Шараф, 1993].

Озак еллар Галимҗан Шәрәфнең сәяси-иҗтимагый эшчәнлеге күләгәдә кала килде. Бары үзгәртеп кору елларында гына аның татар милләте өчен бәһасез хезмәтләре, күзаллаулары киң җәмәгатьчелеккә барып иреште. Шушы елларда Г. Шәрәфнең сәяси эшчәнлеге, язмышы турында матбугатта бер-бер артлы мәкаләләр басылды. Г. Шәрәфнең тууына 100 ел уңаеннан Рәмзи Вәлиевнең архив документларына нигезләнгән «Фаҗига» китабы дөнья күрде [Вәлиев, 1996]. Шәһер Шәрәфнең кызы Сания Шәрәф туплаган Татарстан Республикасының Милли музее фондларында саклanучы язмалардан Шәрәфләр нәселе хакында тулырак мәгълүмат алырга мөмкин [Шараф, 1993].

Г. Шәрәф сәяси һәм иҗтимагый эшчәнлеген Февраль революциясе вакытында ук башлап җибәрә. Ул 1917 елның маенда Мәскәүдә Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаенда «Туфракчылар» фракциясе әгъзасы буларак катнаша. Лингвистика, этнография буенча танылган белгеч булуын, инженер һөнәренә укуын да истә тотып, фракция аңа Идел-Урал штатының чикләрен билгеләү, мәйданын исәпләүне йөкли һәм ул үз проектларын тәкъдим итә. Бу проектларның асылында Россия империясендә компактлы яшәгән территорияләрдә бердәм мөстәкыйль Идел-Урал штаты булдыру ята. Илдә совет власте урнашкач та, ул әлеге юнәлештә эшчәнлеген дәвам итә. Г. Шәрәф – Идел-Урал штатын федерация составындагы мохтариятле җөмһүрият төзү тарафдары.

Шул рәвешле Г. Шәрәф – татар халкының киләчәге өчен мөһим карарлар кабул итүдә катнашкан, вакыйгалар үзәгендә торган күренекле тел галиме, җәмәгать эшлеклесе. Аның гарәп графикасы нигезендәге татар язуына багышланган хезмәтләре бүген дә әһәмиятен югалтмыйлар. Ул төрки халыклар арасында кириллицага, латин һәм шул вакытта гасырлар буе кулланылышта булган гарәп графикасындагы татар язуының ислахына кагылышлы әдәбиятны туплый, өйрәнә. 1921 елдан 1928 елга кадәр барган гарәп графикасындагы татар язуы ислахында катнаша, проектларны тикшерә, үз авторлыгындагы язмалар да тәкъдим итә.

Революциягә кадәр үк төрки халыклар язуын кирилл, латин хәрефләренә күчерү турында матбугатта мәкаләләр басылып килә. Рус миссионерлары Н. Ильминский, И. Яковлев, К. Победоносцев эшчәнлеге нәтиҗәсендә XIX гасырда керәшеннәрдә, кайбер төрки халыкларда кириллица кулланылышка керә.

XX гасыр башында матбугатта аерым бер авторларның фикерләре генә булып күренгән латинчылык революциядән соң сәясәт белән катыш куәтле агымга әверелә. Галимнәр көннән-көн ныгый барган латинчылыкны ике агымга бүлеп карыйлар: гарәп графикасындагы татар язуын латин формаларына яраклаштыру идеясен алга сөрүчеләргә һәм тулаем латин хәрефләрен алу тарафдарларына.

Төрки халыкларда кулланылган гарәп графикасын латин хәрефләренә охшатып ясауны 1857 елда беренчеләрдән булып азәрбайҗан драматургы Фатих Али Ахундов башлап җибәрә. Аның төп фәлсәфи идеясе: төрки дөньяны алга киткән Көнбатыш илләренә якынайту, икътисади яктан бу илләр белән бер үсеш дәрәҗәсенә ирешү һәм төрки халыкларда латин хәрефләрен кулланылышка кертү – шушы юнәлеш эшчәнлегенең бер чагылышы. Соңрак ул Истанбулга китә, үзенең тулаем латин хәрефләренә күчү проектын, рус илчелеге аша, Төркия хакимиятенә җиткерә. Г. Шәрәф күрсәтүенчә, әлеге басмалар танылган әдәбиятчылар Нәмык Кәмал, Әбу Зыя Тәүфыйк һәм Шинаси тарафыннан тәнкыйтьләнә [Шараф, 1926, с. 55].

Бертуган Рәмиевләр, Ә. Мостафин, И. Харитонов, Г. Нугайбәк һәм башкалар гарәп графикасындагы татар язуын латинлаштыру

юнәлешен алып баралар. 1919 елның 4–20 гыйнварында Казанда Гыйльми һәйәт тарафыннан оештырылган «Имля конференциясе»ндә төрки халыкларда кулланылган гарәп язуының структурасын бозуга китерә торган латинлаштыру проектлары кискен рәвештә тәнкыйтьләнә. Шушы проектларны күтәреп чыгучыларның күбесе алга таба кулланылышта булган гарәп язуын тулысынча латин графикасына күчүне яклаучылар төркеменә кушылалар. Г. Шәрәф искәртүенчә, Сәгыйть Рәмиев тә 1920 елларда башкорт латинчылары комитеты эшендә актив катнаша [Шараф, 1926, с. 61]. Әйтергә кирәк, күренекле шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе С. Рәмиев татар-башкортларда латинчылык теориясен эшли һәм аны тормышка ашыруда зур эш башкара. Г. Ибраһимов аны «зур шагыйрь, соңыннан охранник провокатор» дип атый [Ибраһимов, 1924, б. 72] .

Г. Шәрәф 1912–1914 еллар аралыгында гарәп графикасының латинлаштырылган татар язуы проектларының эшләнеш ягыннан иң матурлары арасында И.Н. Харитоновның хәрефләрен дә күрсәтеп уза. Аның авторлыгында 1912 елда үз типографиясендә басылган «Бүләк» әлифбасындагы хәрефләр – гарәп графикасының латинлаштырылган татар язу үрнәкләреннән берсе. Хәзерге вакытта әлифбаның төсле басма нөсхәсе Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана [Харитонов, 1912]. Шушы хәрефләр үрнәген 1926 елда хәрефләр ислахы (реформасы) конкурсына тәкъдим итә, әмма беренче каралышта төшеп кала.

Төрки дөньяда гасырлар буе кулланылышта йөргән гарәп графикасындагы язуны алыштыру мәсьәләсенең актуальләшү сәбәпләрен галимнәр орфографиядәге җитешсезлекләрне хәрефләр алыштыру юлы белән чишү омтылышында күрәләр. Хәреф белән имляның аермасы, шулай ук әлеге мәсьәләнең фәнни чишелешләре турында Г. Алпаров, Г. Шәрәф, Г.Ибраһимов һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә күрсәтелә. Г. Шәрәф әлеге мәсьәләгә түбәндәгечә аңлатма бирә: «Имля мәсьәләсе сүзнең нинди авазга йөргән хәрефләр белән язылуынбасылуын һәм, шул хәрефләр кайбер авазларга җитмәслек булса, шуларны арттыруны тикшерә. Хәреф мәсьәләсе аерым алган авазларга нинди шәкелдәге хәрефләр алынырга тиешлеген, вә бу шәкелләрнең рәсемнәрендә нинди гомуми әсаслар алынырга тиешлеген тикшерә» [Шәрәф, 1923, б. 4].

Г. Шәрәф 1926 елның 26 февраленнән 5 мартына кадәр Бакуда узган Беренче Бөтенсоюз Тюркология съездында чыгыш ясый. Ул «Татарларда һәм төрки халыкларда гарәп һәм латин хәрефләре системасын файдалану мәсьәләләре» дип аталган докладында төрки халыкларда гарәп хәрефләрен калдыру кирәклегенә дәлилләр китерә. «Татарларны гыйльми өйрәнү җәмгыяте хәбәрчесе» журналының оттискы буларак нәшер ителгән хезмәтендә төрле халыкларда кулланылган шрифтларны өйрәнүнең методологиясен эшли, язуда һәм укуда чагыштырулар, параллельләр үткәрә. Гарәп язуына караганда латин һәм рус хәрефләре «уңайлы», «җайлы» диючеләргә ул хәрефләрнең укылыш ягыннан

уңайсыз, киресенчә язуда авыррак булуын, язу тизлегенең сүлпәнлеген, уку агымының акрынлыгын тәҗрибәләр нигезендә аңлатып бирә.

Галим фикеренчә, төрки халыклар өчен латин графикасына күчеш берничек тә алгарыш була алмый, чөнки халыкның гасырлардан килгән язма мәдәнияте бар: «...без латин хәрефләрен алуга караганда, гарәп хәрефләрендән үзгәртелеп бер шәкелгә калдырылган яңа татар хәрефләрен алу күп алда дип табабыз» [Шәрәф, 1923, б. 19].

Галим үзе – гарәп графикасындагы татар язуы ислахы тарафдары. Көн үзәгендә ике яки бер шәкелгә калдырылган гарәп графикасындагы яңа татар басма хәрефләрен тиз арада типография, стенография, телеграфка көйләү мәсьәләләре тора. Г. Шәрәф гарәп графикасындагы татар язуының төзелешен бозмый гына нәсех язуы кысаларында эшләнелгән күчешнең халык өчен дә җиңел узачагын билгели. Хәреф ислахы карарларын гарәп графикасындагы язуны кулланучы барлык төрки халыкларда да гамәлгә кертүнең мөһимлеген ассызыклый. Әлбәттә галим гарәп графикасындагы татар язуының иртәме-соңмы төшеп калачагын аңлый, чөнки латинчылыкны этәрүче көчләр артында Совет хөкүмәте алып барган сәясәт тора. Шуңа да хезмәтләрендә күчеш булган очракта, аны берничә этапта уздыру, латинга караганда рус хәрефләрен алуның отышлырак булуы турында фаразларын әйтеп уза [Шараф, 1926, б. 55].

Типография тамгаларын киметүнең беренче тәҗрибәләре 1907 елда Казан типографиясе һәм словолитниясендә эшләүче Маннан Рәхмәтуллин тарафыннан үткәрелә. Революциягә кадәр үк әлеге юнәлештә эшләр алып барылуга карамастан, алга китеш сизелми. Хәрефләр ислахының идеологы танылган галим Г. Алпаров болай дип яза: «Бер хәрефнең дүрт шәкелдә йөрүе – гарәпнең кульязмасыннан йоккан зур бер хата. Мондан басмада да, мәктәптә дә зур зарар күрәбез. Бердәнбер чара – хәзерге йөргән баш шәкелләрне нигез итеп алыйк та хәрефләрне бер шәкелгә калдырыйк» [Алпаров, 2008, б. 59]

1921 елда ТАССРның Мәгариф Халык Комиссариаты яңа хәрефләр хәзерләү буенча оештырылган ярышта Г. Шәрәф жюри составында була. Ярышта ул вакытларда эшләнелгән проектлар белән Һ. Максуди, М. Идриси, И. Харитонов, Ә. Мостафин, Ш. Тукаев һ.б катнаша. Мөхәммәд Идрисов проекты җиңүче дип табыла. Ул ясаган үрнәкләр буенча остаханәсендә 7 комплект матрица эшләнелә, хәреф коела. Әмма авыр икътисади шартларда бу башлангыч киң кулланылыш тапмый.

Г. Шәрәф басма гарәп шрифтларының үз вариантын эшли. Вакытлы матбугат битләрендә Г. Шәрәфнең 20 нче кегеле кулланыла. 1926 елда ваграк кегельләрнең хәреф коюга тапшырылганлыгын искәртеп үтә [Шараф, 1926, с. 43].

Хәреф ислахының икенче күтәрелеше 1926 елда башлана. Шул елның октябрендә Казанда ТАССРның Мәгариф Халык Комиссариаты Гыйльми үзәге оештырган конференциядә төрек-татар хәрефләренең реформа проектларына ярыш игълан ителә. Әлеге

киңәшмәнең үткәрелү вакыты 1926 елның беренче сентябренә билгеләнгән булса да, катнашучыларның үтенече белән, ул кичектерелә. «Кызыл Татарстан» газетасының 136 нчы номерында игълан ителгән киңәшмә билгеләнгән көнне булмый кала [Кызыл Татарстан, 1926, № 136, б. 4]

Казанда ТАССРның Мәгариф Халык Комиссариаты Гыйльми үзәге тарафыннан басма татар хәрефләре реформасы конференциясе үткәрелү турында игълан янәдән «Кызыл Татарстан» газетасының 1926 елның 16 сентябре санында бирелә. Киңәшмәдә илнең төрле төбәкләреннән, шулай ук Төркиядән дә хәреф төзәтү эшләре белән шөгыльләнүчеләр катнашуы бәян ителә һәм төрле шәһәрләрдән, регионнардан булган вәкилләрнең тулы исемлеге, шөгыльләре күрсәтелә: Кырымнан – Госман Акчураклы; Казакъстаннан – Әхмәд Байтурсин оглы; Мәскәүдән – Мөхәммәд Идрисов; Габдрахман Бурнашев, Уфадан – Шәехзадә Тукаев; Бөредән – хәрефче Гата Исхаки; Казаннан – Галиәсгар Камал; машиначы Шәйхгали; матбагачы Л. Вахидов; хәреф кисүче Ибраһим Зәйнуллин; хәрефчеләрдән Г. Алпаров, Г. Шәрәф, Хәсән Гали. 14. Г. Нугайбәк, 15. Һади Максуди, 16. Г. Измайлов» [Басма татар..., б. 4]

Конференция үзенең эшен 1926 елның 20 октябрендә башлап җибәрә. 23 октябрьдә дә утырышлар дәвам итә, беркетмәләре матбугатта басылып чыга [Кызыл Татарстан. 1926. 27 октябрь].

Әлеге конференциядә типографияләр, язу машиналары өчен һәм шулай ук кульязмада баш хәрефләр шәкелләрен куллану турында сүз бара. Басма, плакат, афиша хәрефләренең төрләнү нигезләре, киләчәктә үсү юллары билгеләнә.

Жюрига барлыгы 150 проект тәкъдим ителә. Ярыш шартлары буенча, катнашучыларга проектларын аерым альбом итеп бастыру таләбе куела. Г. Шәрәф тә үз проектын тәкъдим итә. Хәзерге вакытта әлеге хәреф үрнәкләре белән ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма һәм музыкаль мирас үзәгенең 20 фондында танышырга мөмкин.

Әлеге ярышта илнең төрле төбәкләреннән вәкилләр катнаша. Хәреф комиссиясе проектларга беренчел күзәтү ясый, төзәтмәләр кертә һәм түбәндәге резолюцияне чыгара:

«1. Киңәшмәгә тәкъдим ителгән проектлардан И. Харитонов, Хәсән Гали, Әхмәтҗан Мостафа, Фаик Таһиров, Муллашов проектларында гарәп язуының гомуми күренешен, нигездән үзгәртелгәнлектән, матбугатта гамәлгә үткәрү мөмкин түгел.

2. Иптәш Урманче проекты хәзергә кадәрге басма хәрефләргә нигез булган нәсех язуыннан ераклашканлыктан, гомуми матбугат өчен текст хәреф итеп алына алмый. Ләкин «ай» кебек шәкелләрне төзәтү белән хәреф төрләндерүдә бер стиль итеп алынуы мөмкин табыла.

3. Киңәшмәдә каралган проектлардан (әлифба тәртибе белән) Алпаров, Идрисов, Бурнашев, Тукай, Шәрәф иптәшләрнең бергә калдырылган шәкелләре киңәшмә тарафыннан кабул ителгән әсасларга

муафыйк табылып, болар һәммәсе дә матбугатта текст хәрефе итеп куллану өчен ярасалар да, хәрефләрнең формаларын ачыграк итү һәм бөтен сүз шәкеле күрсәтүләре һәм матурлык ягыннан беркадәр җитешсезлекләре булганлыктан, төзәтмәләр кертелергә тиеш» [Хәреф ислахы турында..., б. 80].

1927 елда ярышның икенче этабы уза. Типография хәрефләренә реформа проектларын карар өчен, ТАССРның Мәгариф Халык Комиссариаты каршында жюри комиссиясе төзелә. Аның рәисе итеп Мөхәммәд Таһиров билгеләнә. Әгъзалар: Зыя Насыйров, Самат Шәрәфетдинов, Галимҗан Шәрәф, Лотфи Вахидов, Бакый Урманче, Гаяз Максудов, Гали Рахим, Ибраһим Кулиев, Габдрахман Измайлов [Типография хәрефләренә..., б. 119]

Конкурска нәтиҗәләр 1927 елның 24 сентябрендә ясала. Мәскәүдән – Мөхәммәд Идрисов һәм Габдрахман Бурнашев, Казаннан Ибраһим Зәйнуллин белән Котдус Фәхретдинов проектлары, Уфадан Шәехзадә Тукаевның афиша хәрефләре проекты сайлана.

«Матурлык, кисү-кою ягыннан иң пөхтә эшләнгән итеп М. Идрисовның төрле кегельләрдә башкарылган проекты беренче урын ала. Икенче урын – Ибраһим Зәйнуллин белән Котдус Фәхретдинов, өченче урын – Шәехзадә Тукаев» [Типография хәрефләренә..., б.119].

Чыннан да, узган гасырның егерменче елларында гарәп графикасындагы татар язуын саклап калу, аның үсешен тәэмин итү өлкәсендә байтак эшләр башкарыла. 1928 елдан реформа нәтиҗәләре өлешчә тормышка да аша, китап басуда һәм вакытлы мабугат битләрендә реформа проектларында катнашучыларның хәреф үрнәкләре кулланыла. Әмма татарлар һәм башка төрки халыклар өчен, латин хәрефләренә күчү белән, әлеге эшчәнлек бөтенләй кулланылыштан төшеп кала.

Г. Шәрәфнең гарәп графикасындагы татар язуы реформасы өлкәсендә эшчәнлеге күпкырлы. Галим, язулы халык буларак, татарларның һәм башка төрки халыкларның гарәп графикасы нигезендәге язуны куллануда дәвам итәргә тиешлеген ассызыклый. Шул чагында гына халык байлыгы булган әдәби мирасның саклануына һәм үсәчәгенә ышана. Совет власте шартларында гарәп графикасындагы татар язуына реформа үткәрүне аны кулланылышта калдыру юлы итеп күрә.

**Әдәбият**

*Алпаров Г.Х.* Сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф. 2008. 287 б.

*Әлтәф Р.* Яла // Идел. 1990. № 9. Б. 35–38.

Басма татар хәрефләре турында киңәшмә // Кызыл Татарстан. 1926. 16 окт.

*Вәлиев Р.* Фаҗига. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. 190 б.

Гарәп хәрефләре реформасы // Кызыл Татарстан. № 136. Б. 4

*Ибраһимов Г.* Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре (1911–1923). Казан, 1924. 143 б.

Латин хәрефләрен алыргамы? Татар хәрефләрен ислах итәргәме? (Фикер алышу нигезендә басыла) // Мәгариф. 1923. № 2, 4. Б. 19; № 3–4. Б. 44–47.

Палятограммы звуков татарского языка сравнительно с русскими //Вестник научного общества татароведения. 1927. № 7. С. 65–103.

*Тәрҗеманов Ж.* Таныттың данымны никадәр илләргә... // Азат хатын. 1989. № 4. Б. 12–14.

Типография хәрефләренә реформа проектларын карар өчен Татарстан Мәгариф халык комиссариаты каршында төзелгән жюри комиссариатының карарлары // Мәгариф. 1927. № 12. Б. 117–119.

*Харитонов И. Н.* Бүләк. Казан, 1912. б. 10 КП-120535

Хәреф ислахы турында Казанда 1926 нчы елның октябрендә җыелган киңәшмәнең карары // Мәгариф. 1926. № 10.

*Шараф Г.* К вопросу о принятии для тюркских народностей латинского шрифта. Казань. 1926. 64 с. КП-22284-205.

*Шараф Г.* Палятограммы звуков татарского языка сравнительно с русским// Вестник научного лбщества татароведения.1927. № 7. С. 65–103.

*Шараф С.Ш.* Родословное дерево Шарафутдина Хуснутдиновича Хуснутдинова (потомков Шараф), 1993. КП-23288.

***Мифтахетдинова Нурия Мидхәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы*
*Милли музееның өлкән фәнни хезмәткәре*